СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№ 5**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Апаз авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 9 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 9 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: В. Әһлиуллин урамында, Чапаев урамының 2 йортыннан 21 нче йортына кадәр яшәүчеләр.

2нче этап: Нагорный урамында, Чапаев урамының 22 йортыннан 55 нче йортына кадәр яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара

салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Чапаев урамының 5 йортыннан 4 йортына кадәр, Тау Өсте урамының 8 йортыннан 12 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;

- В. Әһлиуллин, Чапаев урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;

- янгын гидрантына комплектлау җиһазлары сатып алу (1 данә күләмендә янгын сүндерү өчен җиң, күчерү башы-1 данә., янгын сүндерү колонкасы-1 данә., янгын сүндерү көпшәсе – 1 данә. )

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

5. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 33 йорт, Чапаев урамы, 42А йорт, адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов